

# “Янып калсын гомерең, маяк булып...” (Муса Җәлилнең туына 116 ел)

**Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елда Ырынбур өлкәсе Мостафа авылында туа. Ул кече яшьтән үк зирәк һәм хыялга бай бала була. Күп укый, һәр нәрсәне белергә тырыша. Оста итеп мандолинада уйнарга өйрәнә. Рәсем ясарга ярата**



***Мусаның Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганда төшкән фотосурәте***



Әтисе Мостафа



Әнисе Рәхимә



абыйсы
Ибраһим



сеңлесе
Хәдичә




сеңлесе
Зәйнәп



тормыш иптәше Әминә



М.Җәлил кызы Чулпан белән



**Муса 10-11 яшьләрендә шигырьләр дә язып карый, ләкин алар югала. Матбугатта иң беренче булып унөч яшендә язылган «Бәхет» шигыре (1919) басыла.**
**1922 елда ул Казанга килә һәм 1923-1925 елларда Казан педагогия институтының рабфагында укый.**
**1925 елда Җәлилнең «Барабыз» исемле беренче китабы чыга.**
**«Иптәшкә» (1929) дигән шигырь җыентыгы аның шагыйрь булып җитлегеп килүен тагын бер тапкыр раслый.**



**Ул 1931 елда Мәскәү университетының**

**әдәбият бүлеген тәмамлый.**

**1939 елда Җәлилне Татарстан Язучылар берлегенең җитәкчесе итеп сайлыйлар.**

**Сугышка кадәрге елларда шагыйрь бик күп шигырьләр, җырлар,**

**«Хат ташучы» поэмасын,**

**«Алтынчәч» ,**

**«Илдар» исемле опера либреттоларын яза**

**ҖӘЛИЛ ФРОНТКА КИТӘ.**


**1942 НЧЕ ЕЛНЫҢ ҖӘЕНДӘ ВОЛХОВ ФРОНТЫНДА, ДОШМАН ЧОЛГАНЫШЫНДА КАЛЫП, АВЫР ЯРАЛАНГАН ХӘЛДӘ, ФАШИСТЛАР КУЛЫНА ӘСИРЛЕККӘ ЭЛӘГӘ. ШАГЫЙРЬ ӘСИРЛЕКТӘ ДӘ КӨРӘШНЕ ТУКТАТМЫЙ, ЯШЕРЕН ОЕШМАГА КЕРӘ. ҖӘЛИЛНЕ ҺӘМ АНЫҢ ИПТӘШЛӘРЕН БЕРЛИНДАГЫ МОАБИТ ТӨРМӘСЕНӘ ЯБАЛАР. ШАГЫЙРЬ АНДА ДА ТУГАН ИЛЕНӘ ТУГРЫЛЫКЛЫ БУЛЫП КАЛА, ИСКИТКЕЧ РУХИ НЫКЛЫК КҮРСӘТӘ.**



# Җәлил һәм җәлилчеләр
# Алар безнең күңелләрдә



**Җәлилнең әсирлектә язган шигырьләре бөтен дөньяга билгеле. Татарстанга аның ике дәфтәре кайтты. Аларны халыклар «Моабит дәфтәрләре» дигән исем белән беләләр.**





**Җәлилләр гаиләсенең дүрт буыны:**
**Чулпан, Миша, Татьяна**
**Әминә Җәлил**



# Муса Җәлилнең улы – Альберт Җәлилов

# Ул яшәгән фатирда музей ачылды









# Казандагы Татар дәүләт опера һәм балет академия театры Муса Җәлил исемен йөртә




# Башкалабызның үзәгендә  һәм башка шәһәрләрдә аңа һәйкәл куелды





**Җәлил исемен татар халкы мәңгеләштерде.**
**Муса Җәлилгә багышлап романнар, поэмалар, опера, җырлар, сынлы сәнгать әсәрләре иҗат ителде.**
**Җәлил исемен илебез халкы горурлык белән искә ала.**
**Һәр буын аны йөрәгендә саклый. Аның көрәше һәм эшчәнлеге – күпләр өчен кыюлык һәм батырлык үрнәге**



Муса Җәлил -
Советлар Союзы Герое

СССР Верховный Советы Президиумы
УКАЗЫ
ШАГЫЙРЬ МУСА ҖӘЛИЛГӘ
(М. М. ҖӘЛИЛОВКА)
СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ИСЕМЕ БИРҮ
ТУРЫНДА

Бөек Ватан сугышында немец-фашист илбасарларга каршы сугышларда тиңдәшсез ныклык һәм батырлык күрсәткән өчен, үлүеннән соң, шагыйрь Муса Җәлилгә (Муса Мостафа улы Җәлиловка) Советлар Союзы Герое исеме бирергә.

СССР Верховный Советы
Президиумы Председателе
К. Ворошилов
СССР Верховный Советы
Президиумы Секретаре
Н. Пегов

Мәскәү, Кремль
2 февраль, 1956 ел.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә
Ленин премияләре буенча
СССР Министрлар Советы янындагы комитетта
ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ӨЛКӘСЕНДӘ
АЕРУЧА КҮРЕНЕКЛЕ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН
ЛЕНИН ПРЕМИЯЛӘРЕ БИРҮ ТУРЫНДА

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премияләре комитеты аеруча күренекле әдәбият, музыка, сынлы сәнгать әсәрләре өчен һәм театр сәнгате эшлеклеләренең аеруча күренекле казанышлары өчен 1957 елгы Ленин премияләре бирергә карар бирде:

1. Сергей Тимофеевич Коненковка — «Автопортрет» скульптурасы өчен.
2. Леонид Максимович Леоновка — «Рус урманы» романы өчен.
3. Муса Җәлилгә — «Моабит дәфтәре» исемле шигырьләр циклы өчен.
4. Сергей Сергеевич Прокофьевка — Җиденче симфония өчен.
5. Галина Сергеевна Улановага — балет сәнгате өлкәсендәге күренекле казанышлары өчен.

# ПРЕЗЕНТАЦИЯНЕ «М.ВАХИТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ 2НЧЕ ГИМНАЗИЯ»НЕҢ 6Б СЫЙНЫФЫ УКУЧЫСЫ МИФТАХОВ ӘМИРХАН ӘЗЕРЛӘДЕ